КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2025 ел, 10 март г.Казань № 6-486

Татарстан Республикасы торак пунктлары территорияләрен санитар чистартуны тәэмин итү һәм аларны халыкның экология һәм санитария-эпидемиология иминлеге таләпләренә туры килә торган хәлгә китерүне тәэмин итү максатларында:

1. 2025 елның 1 апреленнән 31 маена кадәр Татарстан Республикасының торак пунктлары территорияләрен чистарту буенча санитария-экология икеайлыгын (алга таба – икеайлык) игълан итәргә.

2. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең башкарма комитетларына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

оешмалар җитәкчеләренә һәм халыкка икеайлык үткәрү турында мәгълүмат җиткерүне;

2025 елның 20 марына кадәр ведомство буйсынуындагы территорияләрне санитар чистарту планнарын әзерләүне һәм расланган планнарны, шулай ук икеайлык үткәрү эшләрен яраштыру өчен төзелгән оператив штаблар турындагы мәгълүматны Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгына җибәрүне;

муниципаль районнар һәм шәһәр округлары территорияләрен төзекләндерү буенча муниципаль кагыйдәләр, калдыклар белән эш итүнең муниципаль кагыйдәләре үтәлешен тикшерүдә тотуны көчәйтү өлешендә җирле үзидарә органнарының административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлары эшен активлаштыруны;

су объектларының су саклау зоналарын, пляжларны, скверларны, паркларны, балалар мәйданчыкларын, азык-төлек һәм кием-салым базарларын, халык күпләп ял итү урыннарын, ял итү базаларын, бакчачылык җәмгыятьләрен һәм гараж кооперативларын, шәхси торак секторы территорияләрен, автомобиль юлларының юл буенча полосаларын санитар чистарту, контейнер мәйданчыкларын төзү һәм ремонтлау, каты көнкүреш калдыклары өчен контейнерлар әзерләү һәм ремонтлау чараларын үткәрүне;

каты көнкүреш һәм биологик калдыклар (үләт базлары) полигоннарын тиешенчә карап тотуны һәм эксплуатацияләүне тәэмин итү һәм алар янындагы урыннарны санитар чистарту буенча чаралар күрүне;

терлекчелек комплекслары калдыкларын рөхсәтсез урнаштыру урыннарын

бетерү буенча чаралар күрүне;

ведомство буйсынуындагы территорияләрне санитар-экологик чистарту эшенә яшьләр (волонтерлар) иҗтимагый оешмаларын ирекле нигездә җәлеп итүне;

«Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасы, «Мәктәп экопатруле» мобиль кушымтасы аша ведомство буйсынуындагы территориядә барлыкка килгән калдыкларны рөхсәтсез урнаштыру урыннары мониторингын гамәлгә ашыруны;

1 һәм 2 нче кушымталарда күрсәтелгән форма буенча икеайлык үткәрү эшләре барышы турындагы мәгълүматны атна саен, чәршәмбе, 12 сәгать 00 минутка кадәр Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгына кертүне.

3. Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгына, Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгына, Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына, Татарстан Республикасының Биология ресурслары буенча дәүләт комитетына, Татарстан Республикасының Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенә, Татарстан Республикасның Дәүләт торак инспекциясенә түбәндәгеләрне гамәлгә ашырырга, шулай ук Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына, Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеген саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә, Табигатьтән файдалану өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Идел-Кама төбәкара идарәсенә, Ветеринария һәм фитосанитария күзәтчелеге федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә бирелгән вәкаләтләр чикләрендә – гамәлгә ашыруны тәкъдим итәргә:

җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү өлкәсендә табигатьне саклау турындагы законнар таләпләрен үтәүгә, махсус сакланыла торган табигать территорияләренең санитария торышына, территорияләрендә төзелеш гамәлгә ашырыла торган җир кишәрлекләренең санитария-экология торышына, торак фондыннан файдалануга һәм аны карап тотуга күзәтчелек итүне һәм аларны тикшерүдә тотуны көчәйтүне;

торак пунктлар, шәһәр яны урманнары, су объектларының су саклау зоналары, автомобиль юлларының һәм тимер юлларның юл буе полосалары, авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге объектлар, халыкның күпләп ял итү урыннары, ял базалары, бакчачылык җәмгыятьләре һәм гараж кооперативлары территорияләрендә калдыкларны рөхсәтсез урнаштыру урыннарын бетерү мәсьәләләренә аерым игътибар бирүне;

«Халык контроле» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасында гражданнарның калдыкларны рөхсәтсез урнаштыру турындагы мөрәҗәгатьләрен үз вакытында һәм сыйфатлы итеп карауны тәэмин итүне.

4. Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгына, Татарстан Республикасының Биология ресурслары буенча дәүләт комитетына, Татарстан Республикасының Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенә, Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясенә түбәндәгене гамәлгә ашырырга, шулай ук Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеген саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә, Табигатьтән

файдалану өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Идел-Кама төбәкара идарәсенә, Ветеринария һәм фитосанитария күзәтчелеге федераль хезмә-тенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә – гамәлгә ашыруны тәкъдим итәргә:

1 нче кушымтада күрсәтелгән форма буенча күзәтчелек чаралары нәтиҗәләре турындагы мәгълүматны атна саен, чәршәмбе, 12 сәгатьб 00 минутка кадәр Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгына җибәрүне.

5. Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына атна саен, чәршәмбе, 3 нче кушымтада бирелгән форма буенча юл өслеген пычратуны булдырмау өлешендә күзәтчелек чаралары нәтиҗәләре турындагы мәгълүматны Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгына җибәрүне тәкъдим итәргә.

6. Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына атна саен, чәршәмбе, икеайлык кысаларында үткәрелгән чаралар нәтиҗәләре турындагы мәгълүматны Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгына җибәрергә.

7. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары территорияләренең санитария-экология торышына рейд тикшерүләрен үткәрү өчен «Матди тәэмин итү идарәсе» дәүләт бюджет учреждениесе тарафыннан Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгына өстәмә күләмдә ягулык-майлау материаллары бирүне тикшерүдә тотуны тәэмин итәргә.

8. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына икеайлык кысаларында Татарстан Республикасында үткәрелә торган эшне массакүләм мәгълүмат чараларында даими яктыртып торуны тәэмин итәргә.

9. Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгына 2025 елның 6 июненә кадәр икеайлык йомгаклары турындагы мәгълүматны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә.

10. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 ел, 12 март, б-504 нче боерыгы үз көчен югалткан дип танырга.

11. Бу боерыкның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2025 ел, 10 март, б-486 нчы
боерыгына 1 нче кушымта

2025 елның «____» ______________на карата
ведомстволар эше турында мәгълүмат

| Т/с | Муниципаль берәмлек исеме | Бозулар ачыкланды | | Калдыкларны рөхсәтсез урнаштыру урыннары ачыкланды | | | Калдыкларны рөхсәтсез урнаштыру урыннары бетерелде | | | Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының (Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының) _______ статьясы буенча беркетмәләр төзелде, данә | | | | Административ җаваплылыкка тартылды | | | | Штрафлар салынды, мең сум | Штрафлар түләтелде, мең сум | Кисәтүләр бирелде |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | барлыгы | шулардан бетерелде | саны, данәсе | мәйданы, кв. метр | күләме, куб.м | саны, данә | мәйданы, кв.метр | күләме, куб.м | барлыгы | юридик затлар | вазыйфаи затлар | гражданнар | барлыгы | юридик затлар | вазыйфаи затлар | гражданнар | | | |
| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |

Җитәкченең фамилиясе, исеме, атасының исеме ____________________________________________________________

*Искәрмә: әлеге кушымтага өстәмә рәвешендә раслый торган фотосурәтләрне (ачыкланды/бетерелде) теркәп, хисап датасына карата мәгълүмат (арта бара торган йомгак белән) бирергә.*

| Т/с | Бозу урыны адресы | Мәйданы, кв.м | Күләме, куб.м | Статусы (бетерелде/бетерелмәде) | Фотоматериал (ачыкланды – бетерелде) |
| --- | --- | --- | --- | --- | --- |
| 1. | | | | | |
| 2. | | | | | |
| 3. | | | | | |

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2025 ел, 10 март, б-486 нчы
боерыгына 2 нче кушымта

Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башкарма комитетларының
2025 елның «___»___________ на карата санитария-экология икеайлыгын үткәрү эшләре барышы турында
мәгълүмат

| Т/с | Муниципаль берәмлек исеме | Чыгарылган каты көнкүреш калдыклары күләме, куб.м | | Махсус автотранспорт җәлеп ителде, берәмлек | Халык катнашты, кеше | Агачлар утыртылды, данә | Куаклар утыртылды, данә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | барлыгы | шул исәптән полигоннарга | | | | |
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |

Җитәкченең фамилиясе, исеме, атасының исеме
_______________________________________________________________

*Искәрмә: Хисап датасына карата мәгълүмат (арта бара торган йомгак белән) бирергә.*

_______________________________

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2025 ел, 10 март, 6-486 нчы
боерыгына 3 нче кушымта

2025 елның «____» _____________ карата Татарстан Республикасы буенча
Эчке эшләр министрлыгы эше турында мәгълүмат

| Т/с | Муниципаль берәмлек исеме | Бозулар ачыкланды | Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 12.33 статьясы буенча беркетмәләр төзелде, данә | | | | Административ җаваплылыкка тартылды | | | | Штрафлар салынды, мең сум | Штрафлар түләтелде, мең сум |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | барлыгы | юридик затлар | вазыйфаи затлар | гражданнар | барлыгы | юридик затлар | вазыйфаи затлар | гражданнар | | |
| | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | |

Җитәкченең фамилиясе, исеме, атасының исеме

___________________________________________________________________

*Искәрмә: Хисап датасына карата мәгълүмат (арта бара торган йомгак белән) бирергә.*

___________________________